# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Санитар хокук бозулар өчен административ
җаваплылык турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы халкының санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелә.

1 статья. Районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне планлаштырганда һәм корганда, объектларны проектлаштырганда, урнаштырганда, төзегәндә (реконструкцияләгәндә) һәм файдалануга тапшырганда санитар кагыйдәләрне бозу

Районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне планлаштырганда һәм корганда, граждан, сәнәга, авыл хуҗалыгы объектларын, инженер челтәрләрен һәм башка объектларны, биналарны һәм корылмаларны проектлаштырганда, урнаштырганда, төзегәндә (реконструкцияләгәндә) һәм файдалануга тапшырганда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

2 статья. Җитештерү, җәмәгать, шул исәптән дәвалау-профилактикалау, торак биналарын һәм урыннарын, транспорт чараларын һәм җайланмаларын эксплуатацияләүнең һәм тотуның санитар кагыйдәләрен бозу

Җитештерү, җәмәгать, шул исәптән дәвалау-профилактикалау, торак биналарын һәм урыннарын, транспорт чараларын һәм җайланмаларын эксплуатацияләүнең һәм тотуның санитар кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып егерме биш минималь күләменә

кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

3 статья. Санитар кагыйдәләргә туры килми торган торак урыннарына урнаштыру, шулай ук вакытлыча яисә даими яшәү өчен яшәргә яраксыз урыннарны гражданнарга бирү

Санитар кагыйдәләргә туры килми торган торак урыннарына урнаштырган, шулай ук вакытлыча яисә даими яшәү өчен яшәргә яраксыз урыннарны гражданнарга биргән өчен -

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, сәнәга предприятиеләре территорияләренең атмосфера һавасын, эш зоналарының, кешеләр даими һәм вакытлыча була торган урыннарның һавасын саклауның санитар кагыйдәләрен бозу

Районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, сәнәга предприятиеләре территорияләренең атмосфера һавасын, эш зоналарының, кешеләр даими һәм вакытлыча була торган урыннарның һавасын саклауның санитар кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Туфракны саклауның, районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең территорияләрен, шәһәр һәм шәһәр яны зоналарындагы урман массивларын, мәдәни-көнкүреш,дәвалау-савыктыру билгеләнешендәге территорияләрне, предприятиеләр һәм оешмалар территорияләрен тотуның санитар кагыйдәләрен бозу

Туфракны саклауның, районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең территорияләрен, шәһәр һәм шәһәр яны зоналарындагы урман массивларын, мәдәни-көнкүреш, дәвалау-савыктыру билгеләнешендәге территорияләрне, предприятиеләр һәм оешмалар территорияләрен тотуның санитар кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып егерме биш минималь күләменә кадәр, гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру, транспортлау, саклау, күмү һәм урнаштыруның санитар кагыйдәләрен бозу

Җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру, транспортлау, саклау, күмү һәм урнаштыруның санитар кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне хуҗалык - эчәр сулар белән тәэмин итүнең санитар кагыйдәләрен бозу

Районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне хуҗалык-эчәр сулар белән тәэмин итүнең санитар кагыйдәләрен бозган өчен -

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка төрле объектларның санитар-яклау зоналарын оештырганда, эксплуатацияләгәндә һәм тотканда санитар кагыйдәләрне бозу

Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка төрле объектларның санитар-яклау зоналарын оештырганда, эксплуатацияләгәндә һәм тотканда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. Механик тирбәлешләр (шау-шу, вибрация) һәм ионлашмаган нурланышлар (югары, аеруча югары һәм гадәттән тыш югары ешлыкларның һәм башка төр нурланышларның электромагнит кырлары) чыганаклары белән эшләр башкарганда санитар кагыйдәләрне бозу

Механик тирбәлешләр (шау-шу, вибрация) һәм ионлашмаган нурланышлар (югары, аеруча югары һәм гадәттән тыш югары ешлыкларның һәм башка төр нурланышларның электромагнит кырлары) чыганаклары белән эшләр башкарганда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең кырыктан алып сиксән минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. Халык куллануы товарларын, азык-төлек продуктларын һәм азык-төлек чималын житештергәндә, кулланганда (файдаланганда), транспортлаганда, саклаганда, шулай ук аларны реализацияләгәндә санитар кагыйдәләрне бозу, шул исәптән житештерүгә, продукциягә, товарга санитария-эпидемиология бәяләмәсе булмау

Халык куллануы товарларын, азык-төлек продуктларын һәм азык-төлек чималын житештергәндә, кулланганда (файдаланганда), транспортлаганда, саклаганда, шулай ук аларны реализацияләгәндә санитар кагыйдәләрен бозган, шул исәптән житештерүгә, продукциягә, товарга санитария-эпидемиология бәяләмәсе булмаган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

11 статья. Махсус жиһазландырылган урыннарда (ашханәләрдә, рестораннарда, кафеларда, барларда һәм башка урыннарда) халыкны тукландыруны оештырганда, шул исәптән ризык һәм эчемлекләр әзерләгәндә, аларны саклаганда һәм халыкка сатканда санитар кагыйдәләрне бозу

Махсус жиһазландырылган урыннарда (ашханәләрдә, рестораннарда, кафеларда, барларда һәм башка урыннарда) халыкны тукландыруны оештырганда, шул исәптән ризык һәм эчемлекләр әзерләгәндә, аларны саклаганда һәм халыкка сатканда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга

хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

12 статья. Санитар кагыйдәләргә туры килү турында дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарыннан бирелгән бәяләмә булмаган килеш яңа технологияләрне, материалларны, матдәләрне, әйберләрне һәм башка продукцияне җитештерүгә кую, кертү һәм куллану

Санитар кагыйдәләргә туры килү турында дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарыннан бирелгән бәяләмә булмаган килеш яңа технологияләрне, материалларны, матдәләрне, әйберләрне һәм башка продукцияне җитештерүгә куйган, керткән һәм кулланган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. Потенциаль куркыныч булган химик, биологик актив матдәләрне һәм иммун-биологик препаратларны җитештергәндә, транспортлаганда, саклаганда һәм кулланганда санитар кагыйдәләрне бозу

Потенциаль куркыныч булган химик, биологик актив матдәләрне һәм иммун-биологик препаратларны җитештергәндә, транспортлаганда, саклаганда һәм кулланганда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

14 статья. Эшкә урнашканда мәҗбүри, башлангыч һәм даими профилактик медицина тикшерүләре, гигиенага өйрәнү һәм (яисә) аттестация узмаган гражданнарга эшләргә рөхсәт итү

Эшкә урнашканда мәҗбүри, башлангыч һәм даими профилактик медицина тикшерүләре, гигиенага өйрәнү һәм (яисә) аттестация узмаган гражданнарга зарарлы эш шартларына, ашамлыкларны, азык-төлек чималын, эчәр суны һәм халык куллануындагы бүтән товарларны җитештерүгә, саклауга, транспортлауга һәм сатуга, балаларны тәрбияләүгә һәм укытуга, халыкка көнкүреш һәм медицина хезмәте күрсәтүгә бәйле эшләрне башкарырга рөхсәт иткән өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр, индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең бердән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

15 статья. Гражданнарның хезмәт, тәрбия һәм өйрәнү шартларына карата санитария-эпедимиология таләпләрен бозу

Гражданнарның хезмәт, тәрбия һәм өйрәнү шартларына карата санитария-эпедимиология таләпләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

16 статья. Карантин, профилактика һәм эпидемиягә каршы гамәлләр башкарганда санитар кагыйдәләрне бозу

Йогышлы һәм йогышсыз массакүләм авыруларның, кешеләрдә агулануларның һәм зарарлануларның барлыкка килүен, таралуын кисәтү, шулай ук бетерү максатында карантин, профилактика һәм эпидемиягә каршы гамәлләр башкарганда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илледән алып ике йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

17 статья. Дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары карарларын һәм күрсәтмәләрен үтәмәү, шулай ук дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген үткәрүгә каршылык күрсәтү

Дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары карарларын һәм күрсәтмәләрен үтәмәгән, шулай ук дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген үткәрүгә каршылык күрсәткән өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

18 статья. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда Татарстан Республикасының баш дәүләт санитария табибы, шәһәрләрнең һәм районнарның баш дәүләт санитария табиблары яисә аларның урынбасарлары тарафыннан карала.

Дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтенең санитар хокук бозулар турындағы эшләрне карарга вәкаләтле урындагы затлары үзләренә бирелгән вәкаләтләр кысаларында һәм бары тик хезмәт вазыйфаларын башкарганда гына әлеге Законда каралган административ чаралар күрелергә мөмкин.

19 статья. Штрафларның суммаларын бүлү

Әлеге закон нигезендә салына торган штрафларның суммалары түбәндәгеләргә җибәрелә: Татарстан Республикасы республика бюджетына - 50 процент күләмендә, хокук бозулар башкарылган урын буенча шәһәрләрнең һәм районнарның бюджетларына - 50 процент күләмендә.

20 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

1.Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 24 феврале
№ 74